ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.03.2022 г. Заинск №154

**«Гражданнарның салым салынырга тиешле кеременең һәм мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен раслау турында»**

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен түбәндәгечә билгеләргә:
1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме:
- ялгыз яшәүче граждан өчен - 33204,99 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен - 21130,46 сум;
- өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен - 18111,82 сум.
1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:
- ялгыз яшәүче граждан өчен -1 218323,70 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен -1 550593,80 сум
- өч кешедән торган гаилә өчен - 1 993620,60 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен - 2 658160,80 сум
- биш кешедән торган гаилә өчен - 3 322701,00 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен - 3 987241,20 сум;
- җиде кешедән торган гаилә өчен - 4 651781,40 сум;
- сигез кешедән торган гаилә өчен -5 316321,60 сум;
- тугыз кешедән торган гаилә өчен - 5 980861,80 сум;
- ун кешедән торган гаилә өчен - 6 645402,00 сум;

2. “Салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен раслау турында” 2021 елның 26 мартындагы 189 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Уртак торак-көнкүреш комиссиясенә гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип таныганда әлеге карарның 1.1, 1.2 пунктлары күрсәткечләрен файдаланырга.

4. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

С.А.Филюшина
Юрист